ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2019 № 262

п.г.т. Алексеевское

**“Алексеевск муниципаль районы милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын раслау турында”гы 03.09.2018 ел, 275 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Федераль законнар таләпләренә туры китерү максатында “Алексеевск муниципаль районы милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын раслау турында”гы 03.09.2018 ел, 275 нче карарына үзгәрешләр кертергә (25.10.2018, 23.11.2018, 04.03.2019, 23.04.2019 үзгәрешләр белән)

**карар бирәм:**

1. 3, 7 - 10 нчы кушымтаның 2.9 пунктында “Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге эчтәлектәге 26 нчы пунктча белән тулыландырырга.

“Хезмәтләр күрсәтүне туктату өчен сәбәп каралмаган.

Хезмәтләр күрсәтүне туктату өчен сәбәпләр:

26) “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы 24 июль, 2007 ел, 209-ФЗ санлы Федераль законның 18 нче маддәсе, 4 нче өлешендә каралган дәүләт милке яки муниципаль милек исемлекләренә кертелгән җир кишәрлеген бирү турында гариза белән кече яки урта эшмәкәрлек субъекты булып тормаучы яки күрсәтелгән Федераль законның 14 нче маддәсе, 23 нче өлеше нигезендә ярдәм күрсәтү мөмкин булмаган зат мөрәҗәгать итте.

2. 4 - 6 нчы кушымтаның 2 нче пункты, 6нчы абзацы, 2,9 пунктчасының “Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

“Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен сәбәпләр каралмаган:

Хезмәт күрсәтүне туктату өчен сәбәпләр:

РФ Җир кодексының 39.15 маддәсе, 1 нче пункты, 2 нче пунктчасында каралган:

2) төзелергә тиешле җир кишәрлеге гариза бирүчегә РФ Җир кодексының 39.16 маддәсе, 1-13, 14_1-19, 22 и 23 пунктчаларында күрсәтелгән сәбәпләр буенча бирелә алмый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Алексеевск муниципаль районы милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М.Р.Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**